Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Татар Ялтаны авыл җирлегенең Изгар авылындагы
гражданнар җыены

КАРАР

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлеге составына керүче Изгар авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 18 ноябре №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2021 елда Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлегенең Изгар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча 2020 елның 18 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- Изгар авылы урамнарында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китерү, грунт салу, гредированиеләү, вак таш салу, грейдированиеләү, кар чистарту)

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 116 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 61 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

**«**РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 61 катнашучысы тавыш бирде;

**«**КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлегенең Изгар авылындагы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. «2021 елда Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлегенең Изгар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге

формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

- Изгар авылы урамнарында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китерү, грунт салу, гредированиеләү, вак таш салу, грейдированиеләү, кар чистарту).

3. Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлегенең Изгар авылы территориясендә 2021 елда үзара салымны, Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлегенең Изгар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә кертергә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Изгар авылы урамнарында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китерү, грунт салу, гредированиеләү, вак таш салу, грейдированиеләү, кар чистарту).

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элеп чыгу юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татар Ялтаны авыл җирлеге
башлыгы ________________ Р.Р. Гарифуллин